**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.12.2019 пгт. Рыбная Слобода №318пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында туризмны үстерү чараларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру буенча эшче төркеме төзү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында туристлык кластерын үстерү бурычларын хәл итү буенча башкарма хакимият органнары һәм башка кызыксынган оешмалар арасында хезмәттәшлекне тәэмин итү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында туризмны үстерү чараларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру буенча эшче төркеме (алга таба- эшче төркеме) төзү һәм аның составын расларга.

2. Кушымтада бирелгән эшче төркеме турында нигезләмәне расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru сайтларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А. К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 09.12.2019 ел,
№318пи карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында туризмны үстерү чараларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру буенча эшче төркеме составы

| | |
|---|---|
| Исланов Р.Л. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, эшче төркеме җитәкчесе; |
| Әхмәтҗанова Ф.Г. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы урынбасары, эшче төркеме җитәкчесе урынбасары (килешү буенча); |
| Вафина А.К. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, эшче төркеме җитәкчесе урынбасары; |
| Бакирова Ф.Р. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» муниципаль казна учреждениесе (МКУ) туризм буенча белгече, эшче төркеме сәркатибе (килешү буенча); |
| Эшче төркеме әгъзалары: | |
| Ризаев Д.Н. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары; |
| Токранов В.И. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары; |
| Магизов М.В. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Ногманова И.М. | Балык Бистәсе муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча); |
| Шакиров И.З. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» муниципаль казна учреждениесе (МКУ) җитәкчесе; |
| Садиков И.М. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе (МКУ) җитәкчесе; |
| Рәшитова Р.А. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль-мәдәни сфера бүлеге» муниципаль казна учреждениесе (МКУ) җитәкчесе; |

| | |
|---|---|
| Гарипова Г.Ш. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балык Бистәсе туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе (МБУ) директоры (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 09.12.2019 ел,
№318пи карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында туризмны үстерү чараларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру буенча эшче төркеме турында нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында туризмны үстерү чараларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру буенча эшче төркеме (алга таба – Эшче төркеме) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында туристлык кластерын үстерү бурычларын хәл итү буенча башкарма хакимиятнең муниципаль органнары һәм башка кызыксынган оешмалар арасында үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү максатларында төзелде.

2. Эшче төркеме үз эшчәнлегендә әлеге Нигезләмәгә таяна.

II. Эшче төркеменең максатлары һәм бурычлары

3. Эшче төркеменең төп максатлары һәм бурычлары булып торалар:

3.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында туристик кластер булдыру һәм үстерү белән бәйле мәсьәләләрне карау:

- оештырылучы рекреацион мәйданнарны туристлык, транспорт һәм башка инфраструктура белән тәэмин итү, туристлык кластеры объектлары иминлегенең бердәм системасын формалаштыру;
- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы туристик кластерын популярлаштыру һәм алга таба үстерү;
- туризм өлкәсе өчен югары квалификацияле кадрлар әзерләү һәм башкалар.

3.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында туристик кластерны үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр формалаштыру.

3.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында туристик кластер булдыру һәм үстерү мәсьәләләре буенча барлык кызыксынган муниципаль башкарма хакимият органнары һәм башка кызыксынган оешмалар белән билгеләнгән тәртиптә килешенгән карарлар кабул итү.

3.4. Утырышларда карау өчен материаллар әзерләү, эшче төркеме компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча алдагы эш планына тәкъдимнәр кертү.

3.5. Эшче төркеме эшчәнлеге нәтиҗәләре турында докладлар әзерләү һәм тәкъдим итү.

III. Эшче төркеменең гамәлдә булу чоры

4. Эшче төркеме, аның алдында куелган максатларны тормышка ашыруга һәм билгеләнгән бурычларны хәл итүгә кадәр оештырыла.

IV. Эшче төркеме составы

5. Эшче төркеме кызыксынган муниципаль хакимият органнары һәм башка җәлеп ителә торган оешмалар тәкъдимнәре нигезендә төзелә һәм Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

V. Эшче төркеменең җитәкче органнары

6. Эшче төркеме җитәкче, җитәкче урынбасарлары, сәркатип һәм эшче төркеме әгъзаларыннан тора.

Эшче төркеме җитәкчесе - Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе. Эшче төркеме җитәкчесе урынбасарлары булып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы урынбасары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары тора.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» хезмәткәре (алга таба - сәркатип) эшче төркеме сәркатибе булып тора.

7. Эшче төркеме җитәкчесе:

- эшче төркеме эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;
- эшче төркеме утырышының көн тәртибен һәм аны үткәрү тәртибен билгели;
- эшче төркеме утырышы беркетмәсенә имза куя;
- эшче төркеме карарларының үтәлешен оештыра;
- җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләрдә эшче төркеме исеменнән чыгыш ясый.

8. Эшче төркеме сәркатибе үз ягыннан түбәндәгеләрне тәэмин итә:

- эшче төркеме утырышлары өчен материаллар әзерләү;
- эшче төркеме әгъзаларына эшче төркеме компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләр, мәгълүмати материаллар әзерләү һәм аларны җибәрү, шулай ук эшче төркеме әгъзаларына чираттагы утырышны уздыру вакыты һәм урыны турында хәбәр итү;
- эшче төркеме утырышларын оештыру;
- эшче төркеме утырышларының беркетмәләрен алып бару;
- эшче төркеме утырышларының нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

9. Аңа йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында эшче төркеме хокуклы:

- эшче төркеме эшчәнлегенә җәлеп итәргә кирәк булганда тиешле тәртиптә эшче төркеме составына кермәгән муниципаль органнар һәм оешмалар вәкилләрен җәлеп итү;
- эшче төркеме әгъзаларыннан үз компетенциясе өлкәсенә керүче мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле материаллар, тәкъдимнәр һәм искәрмәләр соратып алырга һәм билгеләнгән тәртиптә алырга;
- үз компетенциясе өлкәсенә керүче мәсьәләләр буенча эшче төркеме әгъзаларына күрсәтмәләр һәм йөкләмәләр бирергә.

VI. Эшче төркеменең эш тәртибе

10. Эшче төркеме утырышлары кирәк булган саен эш планы нигезендә һәм эшче төркеме җитәкчесе рәислегендәге, ә ул булмаган очракта эшче төркеме җитәкчесе урынбасарларының берсе рәислегендә уздырыла.

11. Эшче төркеме әгъзалары эшче төркеме утырышларында катнашалар, эшче төркеме тарафыннан аның компетенциясе кысаларында карарлар кабул итү турындагы инициативалар белән чыгыш ясыйлар.

12. Эшче төркеме утырышының көн тәртибе проекты һәм тиешле материаллар җитәкче (җитәкче урынбасары) белән килештерү буенча утырыш үткәреләчәк көнгә кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча эшче төркеме сәркатибе тарафыннан аның әгъзаларына кәгазь яисә электрон формада җибәрелә.

13. Эшче төркеме утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Эшче төркеме әгъзасы эшче төркеме утырышында катнаша алмаган очракта, ул карала торган мәсьәләләрнең асылы буенча үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язма рәвештә утырыш үткәрелгәнче бер тәүлектән дә соңга калмыйча, бу хакта эшче төркеме сәркатибенә хәбәр итеп, җибәрергә тиеш, яисә вәкаләтләре билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән язма рәвештә расланган вәкилен җибәрергә мөмкин.

14. Эшче төркеме карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта эшче төркеме җитәкчесенең, ә ул булмаганда - эшче төркеме җитәкчесе урынбасарының тавышы хәлиткеч булып тора.

15. Эшче төркеме утырышында кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, эшче төркеме әгъзасы үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул җаваплы сәркатипкә тапшырыла һәм эшче төркеме утырышы беркетмәсенә теркәлә. Эшче төркеме әгъзасын үз фикерен бәян итү эшче төркеме утырышында кабул ителгән карарларны үтәү зарурлыгыннан азат итми.

16. Эшче төркеме утырышында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә, аларның проектлары эшче төркеме сәркатибе тарафыннан әзерләнә һәм эшче төркеме җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан бер атна эчендә имза куела. Беркетмәнең күчермәсе эшче төркеме утырышы тәмамланганнан соң бер атна эчендә эшче төркеме сәркатибе тарафыннан эш төркеме составына керүче муниципаль органнар, ведомстволар, иҗтимагый һәм башка оешмалар адресына җибәрелә.

## VII. Йомгаклау нигезләмәләре

17. Эшче төркеме турында нигезләмә Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

18. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр эшче төркеме җитәкчесе тәкъдиме буенча эшче төркеме утырышларында кертелә һәм Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән рәсмиләштерелә.